**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«15» ноябрь, 2021 ел Түбән Суык-Су № 20

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә.

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Дуслык, Камышлы, Мазино, Молодежная, Набережная, Новая, Новая Полевая, Полевая, Строителей, Юнусова, 8 Март урамнарында 2021 елның 25 ноябренә 13.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы Заречная, Остров, Парковая, Центральная, Школьная, им.Г.Тукая, им.М.Ждалиля, Садовая, Солнечная, Татарстан, Тынычлык, Успешная, Цветочная, Яшьлек, 70 лет Победы урамнарында 2021 елның 25 ноябренә 16.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Түбән Суык-Су авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1 500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум